МИНИСТЕРСТВО
СЕЛЬСКОГО ХОЗЯЙСТВА
И ПРОДОВОЛЬСТВИЯ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АВЫЛ ХУҖАЛЫГЫ
ҺӘМ АЗЫК-ТӨЛЕК
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

от 02.02.2023 г.Казань № 22/2-пр

«Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2018 елның 21 февралендәге 37/2-пр боерыгы белән расланган «Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы аппаратында биләү коррупциячел хәтәрлекләргә бәйле булган, биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге»нә үзгәреш кертү турында

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык төлек министрлыгының структурасы һәм штат расписаниесе үзгәрүгә бәйле рәвештә, б о е р а м:

«Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2018 елның 21 февралендәге 37/2-пр боерыгы белән расланган «Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы аппаратында биләү коррупциячел хәтәрлекләргә бәйле булган, биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге»нә, аны кушымта итеп бирелүче рекдакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә.

Татарстан Республикасы
Премьер-министры
урынбасары - министр М.А. Җәббаров

Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының 2018 елның 21 февралендәге м 37/2-пр номерлы боерыгы белән расланды (2023 елның 2 февралендәге 22/2-пр номерлы боерыгы редакциясендә)

**Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы аппаратында биләү коррупциячел хәтәрлекләргә бәйле булган, биләгәндә дәүләт граждан хезмәткәрләре үзләренең керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында, шулай ук иренең (хатынының) һәм балигъ булмаган балаларының керемнәре, чыгымнары, мөлкәте һәм мөлкәти характердагы йөкләмәләре турында белешмәләр бирергә тиешле Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәте вазыйфалары исемлеге**

1. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең «җитәкчеләр» категориясе вазыйфалары:

1.1. Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрының беренче урынбасары;

1.2. Татарстан Республикасы авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары;

1.3. Татарстан Республикасы Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгының (алга таба — Министрлык) эшләр идарәчесе;

1.4. Министрлыкның бүлек башлыгы;

1.5. Министрлыкның бүлек башлыгы урынбасары;

1.6. Министрлыкның сектор мөдире;

1.7. Татарстан Республикасы муниципаль районында Министрлыкның Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек идарәсе башлыгы.

1.1.

2. Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәтенең «белгечләр» һәм «тәэмин итүче белгечләр» категориясе вазыйфалары:

2.1. Финанслау бүлегенең әйдәүче киңәшчесе;

2.2. Финанслау бүлегенең әйдәүче белгече;

2.3. Юридик бүлекнең әйдәүче киңәшчесе;

2.4. Юридик бүлекнең әйдәүче белгече;

2.5. Бухгалтерлык исәбе һәм хисап бүлегенең әйдәүче белгече;

2.6. Кадрлар бүлегенең әйдәүче киңәшчесе;

2.7. Кадрлар бүлегенең әйдәүче белгече;

2.8. Аудит һәм коррупциягә каршы эш бүлегенең әйдәүче киңәшчесе;

2.9. Аудит һәм коррупциягә каршы эш бүлегенең әйдәүче белгече;

2.10. Инвестиция сәясәте һәм максатчан программалар бүлегенең әйдәүче киңәшчесе;

2.11. Инвестиция сәясәте һәм максатчан программалар бүлегенең әйдәүче белгече;

2.12. Дәүләт заказы секторының 1 разрядлы өлкән белгече;

2.13. Азык-төлек базарын үстерү бүлегенең әйдәүче киңәшчесе;

2.14. Азык-төлек базарын үстерү бүлегенең әйдәүче белгече;

2.15. Азык-төлек базарын үстерү бүлегенең 1 разрядлы белгече;

2.16. Игенчелек тармакларын үстерү бүлегенең әйдәүче киңәшчесе;

2.17. Игенчелек тармакларын үстерү бүлегенең әйдәүче белгече;

2.18. Инновацион юнәлешләр кертү, үсемлекләрне химияләштерү һәм яклау секторының әйдәүче киңәшчесе;

2.19. Мелиорация, техник һәм җиләк-җимеш культуралары бүлегенең әйдәүче киңәшчесе;

2.20. Мелиорация, техник һәм җиләк-җимеш культуралары бүлегенең әйдәүче белгече;

2.21. Терлекчелек тармакларын үстерү бүлегенең әйдәүче киңәшчесе;

2.22. Терлекчелек тармакларын үстерү бүлегенең әйдәүче белгече;

2.23. Умартачылык һәм аквакультура секторының 1 разрядлы өлкән белгече;

2.24. Нәсел эше һәм терлекләр үрчетү бүлегенең әйдәүче киңәшчесе;

2.25. Нәсел эше һәм терлекләр үрчетү бүлегенең әйдәүче белгече;

2.26. Нәсел эше һәм терлекләр үрчетү бүлегенең 1 разрядлы өлкән белгече;

2.27. Икътисадый анализ һәм планлаштыру бүлегенең әйдәүче киңәшчесе;

2.28. Икътисадый анализ һәм планлаштыру бүлегенең әйдәүче белгече;

2.29. Кече хуҗалыкларны үстерү бүлегенең әйдәүче киңәшчесе;

2.30. Кече хуҗалыкларны үстерү бүлегенең әйдәүче белгече;

2.31. Кече хуҗалыкларны үстерү бүлегенең 1 разрядлы өлкән белгече;

2.32. Авыл кооперациясен үстерү секторының әйдәүче белгече;

2.33. Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләри бүлегенең әйдәүче киңәшчесе;

2.34. Җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр бүлегенең 1 разрядлы өлкән белгече;

2.35. Агросәнәгать комплексын инженер-техник тәэмин итү бүлегенең әйдәүче киңәшчесе;

2.36. Агросәнәгать комплексын инженер-техник тәэмин итү бүлегенең әйдәүче белгече;

2.37. Агросәнәгать комплексын инженер-техник тәэмин итү бүлегенең 1 разрядлы өлкән белгече;

2.38. Техник тәэмин итү секторының әйдәүче киңәшчесе;

2.39. Хезмәтне саклау секторының әйдәүче белгече;

2.40. Оештыру эше бүлегенең әйдәүче белгече;

2.41. Фән, мәгариф һәм инновацион технологияләр бүлегенең әйдәүче киңәшчесе;

2.42. Фән, мәгариф һәм инновацион технологияләр бүлегенең әйдәүче белгече;

2.43. Фән, мәгариф һәм инновацион технологияләр бүлегенең 1 разрядлы өлкән белгече;

2.44. Эшләр алып бару һәм контроль бүлегенең әйдәүче белгече.